БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

8 ноябрь 2021 ел № 83

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында дини оешмаларның гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында» 2010 елның 30 ноябрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, Балтач район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында дини оешмаларның гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия төзергә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында дини оешмаларның гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия Нигезләмәсен расларга (1 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында дини оешмаларның гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия составын расларга (2 нче кушымта).

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» итернет ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин

Балтач район Советының
2021 елның «08» ноябренең
83 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында дини оешмаларның гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия турында

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында дини оешмаларның гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибен билгели (алга таба - комиссия).

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Комиссия тарафыннан аның компетенциясе нигезендә кабул ителгән карарлар вәкаләтле орган тарафыннан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында карарлар кабул итү өчен нигез булып тора.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары

2.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында дини оешмаларның гаризаларын караганда барлыкка килә торган каршылыкларны җайга салу.

2.2. Дини оешмага дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында карар кабул итүгә яисә дини оешма гаризасын карау белән бәйле вәкаләтле органның гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә аларның хокукларын һәм (яки) законлы мәнфәгатьләрен бозу мөмкинлеге турында физик һәм юридик затларның гаризаларын карау.

## 3. Комиссиянең төп функцияләре

3.1. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә:

3.1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүматны сорый.

3.1.2. Үз утырышларында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары, оешмалар вәкилләрен, дин белеме, культурология, хокук һәм башка өлкәләрдә белгечләрне комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча тыңлый.

3.1.3. Үз компетенциясе кысаларында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру яки дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшырудан баш тарту турында вәкаләтле органга тәкъдим белән нигезле карар кабул итә.

## 4. Комиссиянең хокуклары

4.1. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1.1. Комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарын, оешмалар вәкилләрен, дин белеме, культурология, хокук һәм башка өлкәләрдә белгечләрне җәлеп итәргә.

4.1.2. Комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләрне карау өчен эшче төркемнәр төзергә.

## 5. Комиссия эшчәнлеге тәртибе

5.1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карары белән раслана.

5.2. Комиссия составына комиссия рәисе, комиссия секретаре һәм комиссиянең башка әгъзалары керә.

5.3. Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне комиссия рәисе башкара.

5.4. Комиссия утырышлары комиссия карарын таләп итә торган мәсьәләләр килеп чыккан саен, әлеге Нигезләмә нигезендә үткәрелә. Комиссия рәисе карары буенча комиссиянең күчмә утырышлары үткәрелергә мөмкин.

5.5. Комиссия утырышларын чакыру, аларны үткәрү һәм ул кабул иткән карарларның үтәлешен контрольдә тоту комиссия рәисенә йөкләнә. Әгәр утырышта аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала. Комиссия әгъзасы, утырышта катнаша алмаса, карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерләрен язма рәвештә бирергә хокуклы.

5.6. Комиссия карары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул аның рәисе һәм комиссия секретаре тарафыннан имзалана.

Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

Кабул ителгән карар белән килешкән комиссия әгъзаларының аерым фикере комиссия карарына кушымта рәвешендә рәсмиләштерелә.

5.7. Комиссия карары, шулай ук әлеге карар белән килешмәгән комиссия әгъзаларының аерым фикере 7 көн дәвамында интернет челтәрендә урнаштыру өчен вәкаләтле органга җибәрелә.

Балтач район Советының
2021 елның «08» ноябренең
83 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында дини оешмаларның гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия составы

| № | Ф.И.А. | вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Хәйретдинов А.Ф. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Комиссия әгъзалары | | |
| 2. | Фәтхетдинов И.М. | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, рәис урынбасары; |
| 3. | Михайлов Р.А. | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы әйдәп баручы белгече, комиссия секретаре; |
| 4. | Сабирҗанов Н.Н. | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары; |
| 5. | Гайнетдинов И.Ф. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| 6. | Фатыхов Р.С. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының юридик бүлек башлыгы; |
| 7. | Таҗетдинов Р.Ә. | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Иҗтимагый советы җитәкчесе; |
| 8. | (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирлек башлыклары; |